Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче Тоба торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

2022 елның 2 декабре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 2 декабрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге Тоба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатыннардан тыш; күрсәтелгән сумманың 50% күләмендә 2 группа инвалидлар һәм 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар түлиләр, 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

- су челтәрләрен алыштыру (килешү буенча эшләр сатып алу, ташу, түләү, шул исәптән янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру)

«ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 180 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 94 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 94 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Каенлы авыл җирлеге составына керүче Тоба торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес диптанырга.

2.Түбән Кама муниципаль районының Каенлы авыл җирлеге Тоба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатыннардан тыш; күрсәтелгән сумманың

50% күләмендә 2 группа инвалидлар һәм 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар түлиләр, 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә иямәсьәләләрне хәлитүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

- су челтәрләрен алыштыру (килешү буенча эшләр сатып алу, ташу, түләү, шул исәптән янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру)

«ӘЙЕ» «ЮК»

Мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип таныргa.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Каенлы авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4.Әлегекарарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәисле китүче,
Каенлы авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гарипов